Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«26» ноябрь 2021 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2021 елның 26 ноябрендә узган: «2022 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларны карап тоту, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәттә торак пункт чикләрендәге юлларда алга таба вак таш җәю өчен грейдер белән тигезләү һәм тыгызлап нигезен күтәрү буенча хезмәтләр;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт торак пункты чикләрендә юл өслеге профилен үзгәртеп вак таш сатып алу, вак таш түшәү өчен хезмәт күрсәтү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 233 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 130 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 113 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 17 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларны карап тоту, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәттә торак пункт чикләрендәге юлларда алга таба вак таш җәю өчен грейдер белән тигезләү һәм тыгызлап нигезен күтәрү буенча хезмәтләр;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт торак пункты чикләрендә юл өслеге профилен үзгәртеп вак таш сатып алу, вак таш түшәү өчен хезмәт күрсәтү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов